РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» сентябрь 2025 ел г. Альметьевск № 2389

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәтләре сыйфаты стандартларын эшләү, раслау, үзгәртү, юкка чыгару һәм куллану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 23 маендагы 1719 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәтләре сыйфаты стандартларын эшләү, раслау, үзгәртү, юкка чыгару һәм куллану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 23 маендагы 1719 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 17 апрелендәге 1604 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәдәният идарәсенә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсенә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яшьләр эшләре идарәсенә, Әлмәт муниципаль районының үз компетенциясе чикләрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен җаваплы муниципаль учреждениеләренә:»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.3 пунктының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата таләпләр;»;

1.3. Карарга 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 3.1 пунктын түбәндәге

Зак. № 305-2000

редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль хезмәтләр сыйфаты стандарты проектын эшләү Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәдәният идарәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яшьләр эшләре идарәсе, Әлмәт муниципаль районының тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру компетенциясенә кергән муниципаль учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла;»

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А. Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.М. Каюмов